РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИЗМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.04.2026г.

КАРАР
№11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының 12.11.2025 №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Төзелеш Министрлыгының «Дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типовой индикаторларын раслау турында» 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы, РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 12.11.2025 ел, №10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.9 һәм 1.10 пунктлар өстәргә:

«1.9 Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль органы, шулай ук контроль чараларын уздыруга җәлеп ителә торган белгечләр, экспертлар тарафыннан рәсмиләштерелә торган документлар электрон документ рәвешендә төзелә һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

1.10. Профилактик визит үткәрү турында, кисәтү игълан итү турында, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган контроль чараны үткәрү турында карарлар, контроль чараның, профилактик чараның актлары (шул исәптән уздыру мөмкинлеге булмау турындагы актлар), ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр контроль(күзәтчелек) чараларның

бердәм реестрына алар турында белешмәләр кертү юлы һәм аларга кул кую белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән карарларны, актларны һәм күрсәтмәләрне рәсмиләштерү өчен документны аерым төзү таләп ителми.»;

**1.2.** 2.4 нче пунктта түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

- контроль объекты контроль төрләренең Бердәм реестрына белешмәләр кертелгәннән соң хәвеф-хәтәр категорияләренең берсенә кертелгән дип санала.»;

**1.3.** 3.3.3 пунктта "кисәтүгә карата» сүзләреннән соң «, шул исәптән Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша» сүзләрен өстәргә.;

**1.4.** 3.4.2 пунктының 1 подпунктында "видео-конференц-элемтә," сүзеннән соң «Инспектор «мобиль кушымтасыннан файдалану,» сүзләрен өстәргә;

**1.5.** 4.5.5 нче пунктта түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

"Документларны тикшергәндә документлар контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан яисә «Инспектор»мобиль кушымтасыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин.";

**1.6.** 4.9.2 пунктының икенче абзацында «карау гамәлгә ашырылырга» сүзләреннән соң «, шул исәптән пилотсыз аппаратлар (системалар) кулланып, " сүзләрен өстәргә»;

**1.7.** 4.2.5 пунктының икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә өстәргә: "бу чакта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 95 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракларда прокуратура органнары белән килештерү таләп ителми.».

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/izma адреслары буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

**3.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Эзмә авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Әхмәтов